# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**18 ноябрь 2025 ел** **№1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 18 ноябрендә 13.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2026 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

-Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мәктәп ур. юлларның вак таш түшәмәсен ремонтлау (вак ташу), Сөлек торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);)

-Ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү; (зиратны киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу;)

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторының ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу; Сөлек т. п. ш. Школьная урамындагы зур агачларны кисү;)? »;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 124 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 74 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 74 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл жирлегенең Сөлек авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2026 елда 500 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

-Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мәктәп ур. юлларның вак таш түшәмәсен ремонтлау (вак ташу), Сөлек торак пунктында юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);)

-Ремонт, киртәләр кору, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү; (зиратны киртәләү өчен төзелеш материаллары сатып алу;)

- Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторының ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу; Сөлек т. п. ш. Школьная урамындагы зур агачларны кисү;) »; кабул ителгән.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Шәрләрәмә авыл җирлегенең Сөлек мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче Н.Н.Хуҗина